**2021 елда Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләү турында мәгълүмат**

2021 елда Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында гражданнар тарафыннан язмача җибәрелгән һәм шәхси кабул итүдә алынган **8933** мөрәҗәгать карап тикшерелде (2020 елда – 8824).

Барлык кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан:

**5475**е – язмача мөрәҗәгатьләр (2020 елда – 6025).

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә **7223** имза белән **265** коллектив мөрәҗәгать керде.

Шәһәр Хакименә һәм Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә шәһәр халкын борчыган мәсьәләләрне хәл иткән өчен рәхмәт белдерелгән **40** мөрәҗәгать алынды.

**5475** мөрәҗәгатьнең **1005**е уңай хәл ителде һәм бу гомуми санның **18,3 %** ын тәшкил итте, **188**е ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелде, калган мөрәҗәгатьләр буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Үзләренең социаль хәлен күрсәтүчеләрнең составы түбәндәге категория гражданнарга бүленә:

- пенсионерлар: **365** (6,67 %);
- эшләүчеләр: **238** (4,35 %);
- эшсезләр: **73** (1,33 %);
- эшмәкәрләр: **56** (1,02 %);
- хезмәткәрләр: **55** (1,00 %);
- хуҗабикәләр: **47** (0,86 %);
- интеллигенция: **28** (0,51 %)
- укучылар: **20** (0,37 %);
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: **4593** (83,89 %).

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үзенең льготалы категориягә ия булуын күрсәтүчеләрнең күпчелеге: инвалидлар – **204** (3,73 %), күп балалы гаиләләр – **143** (2,61 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – **22** (0,40 %), ялгыз ата-аналар – **18** (0,33 %), Бөек Ватан сугышы ветераннары – **4** (0,07 %).

Гражданнардан кергән язмача мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, 2021 елда шәһәр халкы өчен түбәндәге мәсьәләләр аеруча актуаль саналган:

- торак-коммуналь хуҗалыгы – **1820** (2020 – 1827);
- төзелеш – **573** (2020 – 455);

- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия бирү – **442** (2020 – 563);

- юл хуҗалыгы – **426** (2020 – 548);

- җирдән файдалану – **419** (2020 – 365);

- торак өлкәсе – **344** (2020 – 428);

- социаль тәэмин итү – **269** (2020 – 392);

- сәламәтлек саклау – **239** (2020 – 211);

- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – **204** (2020 – 206);

- транспорт хезмәте күрсәтү – **190** (2020 – 205);

- законлылык һәм хокук тәртибен тәэмин итү – **120** (2020 – 195);

- финанс өлкәсе – **115** (2020 – 106);

- хезмәт һәм эш белән тәэмин итү – **64** (2020 – 160);

- төрле характердагы мәсьәләләр – **250** (2020 – 364).

**3458** чаллылы шәхси кабул итүдә булган (2020 – 2799).

**1284** мөрәҗәгать буенча чаралар күрелде, мөрәҗәгать иткән **2174** граждан аңлатмалар алды.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан **296** чаллылы турыдан-туры кабул ителде.

Гражданнардан алынган бер генә мөрәҗәгать тә җирле үзидарә органнарында игътибарсыз калмый.

Кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы көн саен уздырыла, мөрәҗәгатьләрне үзвакытында карап тикшерү контрольдә тотыла, үтәү дисциплинасы буенча анализ ясала.

Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Мөрәҗәгать итүче һәр кешегә гамәлдәге законнарга нигезләнеп язмача җаваплар һәм аңлатмалар бирелде.